# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

**(IV чакырылыш)**

## КАРАР

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

14 май 2021 ел № 46 Урыссу ш.т.п.

Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 30 март, №13 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Дәүләт органнарында дәүләт гражданлык хезмәткәрләре реестрларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 12.02.2001 ел, № УП-132 Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 28.04.2020 ел, № 18 карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре реестрларын алып бару эшчәнлеген камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында Ютазы район Советының 2016 елның 30 мартындагы №13 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта "шулай ук кәгазь төрдә аларда булган мәгълүматка рөхсәтсез керү, юк итү, модификацияләү, блоклау, күчермә ясау, тапшыру, тарату, шулай ук хокуксыз гамәллләрдән саклауны тәэмин итеп" сүзләрен төшереп калдырырга ;

6 пунктта «кәгазь төрдә дә» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

11 пунктның икенче абзацында «атасының исеме» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

21 пунктта «шулай ук кәгазь төрдә» сүзләрен төшереп калдырырга;

22 пунктны төшереп калдырырга;

23 пунктны 22 пункт дип санарга;

22 пунктта "кәгазь төрдә" сүзләреннән соң «(1997 елдан 2020 елга кадәр)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Официальный Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм авыл җирлекләре Советлары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин